ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2026 п.г.т.Алексеевское № 227

**Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы Башкарма комитеты
каршындагы эшмәкәрләр Советы турында**

«Республика башкарма хакимият органы каршындагы иҗтимагый совет турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карарына туры китереп

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында эшмәкәрләр Советы төзергә.
2. Расларга:

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы эшмәкәрләр советы турында Нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы эшмәкәрләр Советы составын (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы эшмәкәрләр Составы турында» 05.04.2012 ел, № 181 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет
Җитәкчесе** **О. Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_10.06.2026_ № _227_
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы эшмәкәрләр Советы турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы эшмәкәрләр Советы (алга таба - Совет) эшчәнлеген оештыру максатын, бурычын һәм нигезләрен билгели.

1.2. Совет Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) каршындагы даими эшләүче киңәшмә органы булып тора.

1.3. Совет карары рекомендация характерында.

1.4. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте актларына, башка норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.5. Совет ирекле катнашу нигезендә төзелә.

1.6. Совет әгъзалары үз вазыйфаларын иҗтимагый башлангычларда башкаралар.

1.7. Совет эшчәнлеге барлык мәсьәләләр буенча ирекле фикер алышу һәм коллектив карар кабул итү нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Советның максат һәм бурычлары

2.1. Совет түбәндәге максатларында төзелә:

кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда эшмәкәрләрнең ихтыяҗ һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, Россия Федерациясе гражданнарының хокук һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең хокукларын яклау;

кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү, уңайлы инвестиция климаты булдыру һәм Алексеевск муниципаль районының инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыру мәсьәләләре буенча төп юнәлешләрне эшләүгә иҗтимагый, һөнәри һәм иҗат берләшмәләре вәкилләрен җәлеп итү, Башкарма комитет эшчәнлегенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принципларын тормышка ашыру.

2.2. Советның төп бурычлары булып тора:

кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне камилләштерү, уңайлы инвестиция климаты булдыру һәм Алексеевск муниципаль районының инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә, уңайлы инвестиция климаты булдыру һәм Алексеевск муниципаль районының инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыру мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү;

Башкарма комитет карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

2.3. Советның топ бурычларын хәл иткәндә:

Башкарма комитет җитәкчесе белән килештереп, совет әгъзалары Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы коллегиясе утырышларында һәм Башкарма комитетның төп оештыру чаралары планы нигезендә үткәрелә торган башка чараларда катнашырга хокуклы.

Совет Башкарма комитеттан үз вәкаләтләрен үтәү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга мөмкин, моңа дәүләт серен һәм федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүмат керми.

## 3. Советны төзү тәртибе

3.1. Совет әгъзалары булып унсигез яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданнары тора ала.

3.2. Совет составына иҗтимагый һәм дини оешмалар (берләшмәләр), массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, тиешле өлкәләрдәге галимнәр, белгечләр керергә мөмкин.

3.3. Совет 15 кешедән артмый төзелә.

3.4. Советның шәхси составы Башкарма комитет карары белән раслана. Совет составына өстәмә катнашучыларны кертү мәсьәләсе Совет утырышында карала, тәкъдим тиешле карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

3.5. Совет рәисләрдән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм совет әгъзаларыннан тора.

3.6. Совет рәисе, рәис урынбасары, секретаре, әгәр алар өчен Совет Әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы тавыш биргән булса, Совет әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән Советның беренче утырышында сайлана. Совет рәисен һәм урынбасарын сайлау турындагы карар совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Совет рәисе утырышны алып бара, утырыш беркетмәсенә кул куя.

Рәис урынбасары ул булмаганда рәис вазыйфаларын башкара.

Совет утырышы секретаре утырыш беркетмәсен төзи, аны имзалаганнан соң Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрә.

3.7. Совет рәисен яисә рәис урынбасарын вазыйфаларыннан азат итү мәсьәләсе аларның шәхси гаризасы яисә Советның барлык әгъзаларының биштән береннән артыграгы тәкъдиме буенча Совет тарафыннан карала. Карар өчен

Совет Әгъзаларының гомуми санынnan яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала.

3.8. Совет әгъзалыгын туктату башкарма комитет җитәкчесенең совет әгъзасының язма гаризасы йә Совет рәисенең тәкъдиме нигезендә кабул ителә торган карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Совет эшчәнлеген оештыру

4.1. Совет эшчәнлегенең төп формасы кварталга кимендә бер мәртәбә уздырыла торган утырышлардан гыйбарәт.

Әгәр анда Советның исемлек составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, Совет утырышы тулы хокуклы дип санала. Карар аның өчен утырышта катнашучы Совет әгъзаларының яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала.

4.2. Совет утырышларында Башкарма комитет вәкилләре катнашырга хокуклы.

4.3. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Башкарма комитетлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.4. Утырыш нәтиҗәләре буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа Совет рәисе (яисә рәис булмаганда урынбасары) һәм секретаре имза сала. Имзаланган беркетмә җирле үзидарә органы карарлар кабул иткәндә эшмәкәрләр фикерен исәпкә алуда файдалану өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г. Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_10.06.2026_ № _227_
карарына 2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы эшмәкәрләр Советы Составы**

| | |
|---|---|
| Сафина Г.Т. | «Эдем» ҖЧЖ директоры-Совет рәисе (килештерү буенча); |
| Зиннәтуллин И.А. | «Зиннәтуллин И. А.» КФХ башлыгы (килештерү буенча); |
| Соловьев А.Г. | «Алексеевский кабельный завод» ҖЧЖ директоры (килештерү буенча); |
| Тюкарев Ю.И. | Алексеевск муниципаль районының авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы (килештерү буенча); |
| Вәлиев Р.Ф. | «Мостовик» ҖЧЖ директоры (килештерү буенча); |
| Вәлиев М.Ш. | «Алексеевск МСО-ТАПС» ҖЧЖ генераль директоры (килештерү буенча); |
| Мөхәммәтшин Р.Н. | «Татмаш заводы» ҖЧЖ генераль директоры (килештерү буенча); |
| Усманов Т.Н. | «Метус» ҖЧЖ гамәлгә куючысы (килештерү буенча); |
| Гайнуллин О.А. | «Хәмитов Р. М.» КФХ башлыгы урынбасары (килештерү буенча); |
| Хәмитшин Н.У. | «Шәмәрдән» авыл хуҗалыгы кулланучыларының эшкәртү, тәэмин итү, сату кооперативы идарәсе рәисе (килештерү буенча); |
| Ахманаева Е.Д. | «Заря» («Таң») газетасының баш мөхәррире (килештерү буенча). |